Республика Татарстан
Руководитель Исполнительного
комитета Кадыровского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул. Молодежная , д. 1, с. Кадырово,
Заинский район, 423513

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлегенең
башкарма комитеты
җитәкчесе

Яшьләр урамы, 1 нче йорт, Кадер авылы,
Зәй районы, 423513

Телефон, факс 63-3-18. Электронный адрес: Kadir.zai@tatar.ru, сайт: www.Kadirovo.ukoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26.03.2018 ел** **№ 4**

**«2015 – 2018 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүнең муниципаль программасы турында» 2015 елның 04 июнендәге 11 номерлы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. «2015 – 2018 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүнең муниципаль программасы турында» 2015 елның 04 июнендәге 11 номерлы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларын (ярдәмчепрограммаларын), Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), муниципаль программаларны (ярдәмче программаларын) гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган

муниципаль хокукый актларда билгеләнгән шартларга туры килә торган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының әлеге программаларда (подпрограммаларда) катнашуга бертигез тигез керүе);»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 8.1 пунктны өстәргә:

«8.1. **Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү**

Ярдәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, торак булмаган биналарны, җиһазларны, машиналарны, механизмнарны, җайланмаларны, транспорт чараларын, инвентарьларны, инструментларны, түләүсез нигездә яки ташламалы шартларда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программалары (ярдәмче программалар), муниципаль программалар (ярдәмче программалар) нигезендә файдалануга тапшыру рәвешендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән мөлкәт максатчан билгеләнеше буенча файдаланылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Кадер авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.М.Нуруллин**